**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16 сентябрь 2026 ел № 1186

**2027 елга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне 2027 елга расларга:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү мәктәп-интернатларында тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар;

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының финанс-бюджет мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2027 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2026 елның 16 сентябрендәге 1186 номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү мәктәп-интернатларында тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнар**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Урнашкан территориясе | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сумнар |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | Шәһәр җирлеге | 144690 |
| | Авыл җирлеге | 145980 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | Шәһәр җирлеге | 220493 |
| | Авыл җирлеге | 225102 |